**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы №94 24.04.2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 декабрендәге 122 номерлы Микулино авыл җирлеге советы карарына үзгәреш кертү хакында (29.10.2015 №12 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12 номерлы карар редакциясендә), 2 пунктның 3 пунктындагы дүртенче абзацында «бер торак урын (торак йорт) сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: И.А.Такиулин